**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы**

**Емелькино авыл җирлеге советы**

**КАРАР**

№ 1 28 январь 2015 ел.

Емелькино авыл җирлеге Советы башлыгының 2014 елда авыл җирлегенең социаль – икътисади үсеше нәтиҗәләре һәм 2015 елга фараз турында хисабы

Емелькино авыл җирлеге Советы башлыгының 2014 елда социаль – икътисадый үсеш йомгаклары һәм 2015 елга фараз турында хисабын тыңлап һәм фикер алышып. Авыл җирлеге советы 2014 елда авыл җирлеге халкы мәнфәгатьләрендә, «РФда җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясенең 6.10.2003 елдагы 131-ФЗ номерлы Законы һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елдагы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнгән компетенция һәм вәкаләтләр нигезендә эшләр башкарды карар кабул итте:

1. Емелькино авыл җирлеге Советы башлыгының 2014 елда авыл җирлегенең социаль – икътисади үсеше нәтиҗәләре һәм 2015 елга фараз турында хисабын игътибарга алырга.

2. 2014 елда авыл җирлеген социаль – икътисади үстерүнең төп бурычы булып халыкның тормыш сыйфаты үсешен тәэмин итү санала.

3. Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә аерым игътибар бирергә.

4. Кредитлау һәм торак төзелеше өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган программаларның мөмкинлекләрен авылда яшьләрне ныгыту өчен максималь файдалану.

5. Халыкның тормыш дәрәҗәсен төшерүгә юл куймау һәм гражданнарның социаль хезмәтләргә тигез керү мөмкинлеген тәэмин итү буенча чаралар күрергә.

6. Хокук саклау органнары белән берлектә җәмәгать иминлеге дәрәҗәсен күтәрү һәм җәмәгать тәртибен, гражданнарның тормышын һәм сәламәтлеген һәм дәрәҗәсен ышанычлырак яклауны тәэмин итү буенча алга таба эш алып барырга.

7. Торак пунктларны төзекләндерү, яшелләндерү һәм чистарту, экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча чараларны дәвам итәргә.

8. Авыл җирлеге башкарма комитетына хисап докладында һәм аны тикшергәндә әйтелгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне үтәү буенча чаралар планын эшләргә тәкъдим итәргә.

9. Авыл җирлеге Советы аппаратына хисап докладында һәм аны тикшергәндә әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гомумиләштерергә.

10. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http:aksubaevo.tatarstan.ru.

11. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Емелькино авыл җирлеге Советының даими комиссияләренә йөкләргә.

Емелькино авыл җирлеге башлыгы Н.И.Михайлова